ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11. 11. 2020 г. Заинск № 506

**«2020 елда Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәре» район конкурсы турында нигезләмәне раслау хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында" 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2020 елда Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәре» район конкурсы турында нигезләмәне расларга (1 кушымта).
2. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре арасында 2020 ел эш нәтиҗәләре буенча конкурска йомгак ясау өчен комиссия составын расларга (2 кушымта).
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районы массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **М.И.Захарова**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 11 ноябрь
506 номерлы карарына
1 кушымта

**«2020 елда Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәре» район конкурсы турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. "Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының 2020 елда иң яхшы хезмәткәре" район конкурсы турында нигезләмә конкурс үткәрүнең максатын, бурычларын, аны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсның төп максатлары булып тора:

агросәнәгать комплексы хезмәткәрләренең эш нәтиҗәлелеген арттыру;

аларны үстерү һәм кызыксындыру;

тармакның иң яхшы хезмәткәрләрен ачыклау.

1.3. Конкурс номинацияләр буенча үткәрелә.

1.4. Конкурста катнашу өчен гаризалар, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, Зәй муниципаль районы территориясендә эшләүче агросәнәгать комплексы оешмаларыннан кабул ителә.

1.5. Конкурсны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зәй муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча) оештыра.

1.6. Финанслау Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар хисабына гамәлгә ашырыла.

1.7. Район Башкарма комитеты бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора.

1.8. Җиңүчеләрне бүләкләү өчен грант акчаларының гомуми күләме 2998 156 сум тәшкил итә. Каралган грантларның гомуми саны-125.

## 2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

2.1. Конкурсның башлануы - әлеге карарны Зәй муниципаль районының массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару көне.

2.2. Конкурска гаризаларны кабул итү вакыты конкурс үткәрү турында игълан бастырылганнан соң 30 көн дәвамында. Конкурста катнашу өчен бер генә гаризасы да бирелмәгән очракта, конкурс узмаган дип санала.

2.3. Конкурска йомгак ясау һәм 2020 елгы эш нәтиҗәләре буенча җиңүчеләрне билгеләү гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә уздырыла.

2.4. Конкурс, анда катнашу тәртибе, үткәрү формасы турында мәгълүмат ачык булып тора, ул массакүләм мәгълүмат чараларында, Зәй муниципаль районы сайтында, "Интернет" челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында урнаштырыла.

2.5. Документларны тапшыру вакыты, тәртибе:

Документлар комиссиягә заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң 5 календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Документлар кәгазь чыганакта, махсус Зәй муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә бирелә.

Конкурста катнашу өчен комиссиягә бирергә кирәк:

- конкурста катнашуга заявка (әлеге нигезләмәгә1 нче кушымта)
- заявка бирү аеннан алдагы айның беренче числосына кадәр бирелгән юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан тиешенчә расланган өземтә
- җитәкче тарафыннан расланган предприятие Уставының күчермәсен
- тикшерүләр үткәрүгә ризалык (гаризага 1 нче кушымта)
- салым органыннан бурыч булмау турында белешмә
- җитәкче имзасы һәм мөһере белән расланган кушымта итеп бирелә торган формалар буенча мәгълүмат (әлеге нигезләмәнең 2-13 нче кушымтасы).

2.6. 2020 ел авыл хуҗалыгы эш нәтиҗәләренә йомгак ясау һәм бүләкләнүче хезмәткәрләрне билгеләү комиссиясе Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге карары белән төзелә (карарга 2 нче кушымта).

Конкурс комиссиясе документларны кабул итү датасы тәмамланган көннән алып 5 календарь көн эчендә белешмәләрне карый, Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән алынган мәгълүматны тәкъдим ителгән номинацияләр буенча өйрәнә.

2020 елгы эш йомгаклары буенча иң югары нәтиҗәләргә ирешкән авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләре (терлекчелек буенча 2020 елның 9 аенда) әлеге нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән номинацияләр буенча бүләкләнәләр.

2.7. Комиссия утырышын комиссия рәисе үткәрә.

2.8. Йомгак ясау документларны кабул итү срогы тәмамланган көннән алып комиссия тарафыннан 5 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, конкурс комиссиясе рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.9. Эш башкару комиссия секретарена йөкләнгән.

2.10. Конкурста сайлап алуда катнаштырудан баш тарту өчен конкурста катнашучының түбәндәге таләпләргә туры килмәве нигез булып тора (алга таба - сайлап алу):

сайлап алуда катнашучы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше, тулаем алганда, 50 процентган артып китә торган, аның теркәү урыны-дәүләт (территория), Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яисә) финанс операцияләрен (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләт һәм территорияләр исемлегенә кертелгән Россия юридик заты булып тормый,

сайлап алуда катнашучы агымдагы финанс елында грантны бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан хокукый акт белән билгеләнгән максатларга башка хокукый актлар нигезендә акчалар алмаган;

заявка бирү датасына сайлап алуда катнашучының хокукый акт, субсидияләр, бюджет инвестицияләре буенча шул исәптән башка хокукый

актлар нигезендә грант бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына, һәм әгәр мондый таләп хокукый актта каралган булса, хокукый акт нигезендә грант бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты алдындагы башка срогы чыккан бурычлары булмау;

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гариза бирелгән көнгә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау;

юридик зат булган сайлап алуда катнашучы заявка бирү датасына ликвидация, реорганизация процессында булмаска, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән булырга тиеш, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгел, ә шәхси эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган булырга тиеш.

2.11. Конкурста катнашучыга акчалата бүләк бирүдән баш тарту өчен нигез:

- конкурста катнашучы тарафыннан бирелгән документларның 2.4 пунктчада билгеләнгән документлар таләпләренә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- акчалата бүләк алучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

2.12. Гаризаларны карау һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре буенча конкурста җиңүчеләр белән 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта грант бирү турында килешү төзелә.

2.13. Сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре, сайлап алуда катнашучылар, рейтинг һәм (яисә) сайлап алу критерийлары буенча бәяләүләр, сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнгән акчалата бүләкләүләрне алучылар, бирелә торган бүләкләү күләмнәре турында мәгълүмат Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru/) йомгаклар ясаганнан соң 7 көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

2.14. Бүләкләүләр бирүнең максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылыкны билгеләү максатларында авыл хуҗалыгы оешмасы дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүенең баш бүлүчесе һәм вәкаләтле органы тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә ризалык бирә (гаризага 1 кушымта).

## 3. Номинацияләр, бүләкле урыннар саны һәм кызыксындыру суммалары.

2020 ел эш йомгаклары буенча иң югары нәтиҗәләргә ирешкән Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләре (терлекчелек буенча 2020 елның 9 аенда) түбәндәге номинацияләр буенча бүләкләнүгә дәгъва итә:

3.1. **"Бөртекле культураларны урып җыюда алдынгы комбайнчылар"** - грант Зәй муниципаль районында ашлык суктырган комбайнчылар экипажларына бирелә:

2500 - 3499 тонна ашлык суктыручылар – 20 грант, 50 000 әр сум.

3500 тоннадан алып, 4499 тоннага кадәр – 16 грант, 70 000 әр сум.

4500 тонна һәм аннан да күбрәк тонна – 4 грант, 100 000 әр сум.

Экипаж арасында премия суммасы 60/40 нисбәтендә бүленә (60% механизаторга, 40% механизатор ярдәмчесенә) (гомуми сумма – 2 520 000 сум);

3.2. **”Шикәр чөгендерен җыеп алуда алдынгы механизаторлар”,** Зәй муниципаль районында иң күп гектарда шикәр чөгендере казыган 10 алдынгы механизаторга 5747шәр сум грант бирелә (гомуми сумма - 57470 сум);

3.3. **«Шикәр чөгендерен төяүдә алдынгы механизаторлар»,** Зәй муниципаль районында иң күп тонна шикәр чөгендере төягән 2 алдынгы механизаторга 5747шәр сум грант бирелә (гомуми сумма – 11 494 сум);

3.4. **“Басуларны корткычларга, авыруларга, чүп үләннәренә каршы эшкәртүдә алдынгы механизаторлар”,** Зәй муниципаль районында басуларны иң күп гектарда эшкәртүче 5 алдынгы механизаторга 5747шәр сум грант бирелә (гомуми сумма - 28 735 сум);

3.5. **“Туфракны чәчү алды эшкәртүендә, уҗым культуралары чәчүдә һәм ашлама кертүдә алдынгы механизаторлар”,** Зәй муниципаль районында иң күп гектарда эш башкарган 5 алдынгы механизаторга 4598әр сум грант бирелә (гомуми сумма – 22990 сум);

3.6. **“Печән чабуда алдынгы механизаторлар”,** Зәй муниципаль районында иң күп гектарда печән чапкан 6 алдынгы механизаторга 5747шәр сум грант бирелә (гомуми сумма - 34482 сум);

3.7. **“Терлек азыгы әзерләүдә алдынгы механизаторлар”,** Зәй муниципаль районында иң күп күләмдә (тонна) азык әзерләгән 4 алдынгы механизаторга 5747шәр сум грант бирелә (гомуми сумма - 22988 сум);

3.8. **“Туфрак эшкәртүдә алдынгы механизаторлар”,** Зәй муниципаль районында эталон гектарларда иң күп җир эшкәрткән 10 алдынгы механизаторга 4598әр сум грант бирелә (гомуми сумма - 45980 сум);

3.9. **“Алдынгы машина йөртүчеләр”,** Зәй муниципаль районында тонна-километрларда иң күп эш башкарган 10 алдынгы машина йөртүчегә 5747шәр сум грант бирелә (гомуми сумма - 57470 сум);

3.10. **“Машина белән савуда алдынгы операторлар”,** бер баш сыерга иң күп күләмдә (килограммнарда) сөт сауган 5 алдынгы операторга 5747шәр сум грант бирелә (гомуми сумма - 28735 сум);

3.11. **“Алдынгы терлекчеләр, бозау караучылар”,** граммнарда иң күп уртача тәүлеклек артым алган 6 алдынгы терлекче, бозау караучыга 4598әр сум грант бирелә (гомуми сумма – 27 588 сум).

3.12. **"Иң яхшы җитештерү комплексы идарәчесе һәм хуҗалыкның иң яхшы белгечләре»** - иң яхшы җитештерү күрсәткечләренә ирешкән (бөртекле культуралар буенча уңыш, шикәр чөгендере буенча уңыш, 1 сыердан савым, ит җитештерү) 16 алдынгы хезмәткәргә (җитештерү комплексларының идарәчеләре һәм хуҗалыклар белгечләре), җитештерү комплекслары идарәчеләренә -6896шар сум, хуҗалык белгечләренә 4598әр сум грант бирелә (гомуми сумма – 91952 сум).

3.13. **«Авыл хуҗалыгы җитештерүе алдынгылары»,** бу номинациядә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хатлары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының Рәхмәт хатлары, министрлыкларның һәм ведомстволарның Мактау грамоталары, «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» мактаулы исеменә ия, Зәй муниципаль районы башлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнгән хезмәткәрләр бүләкләнә. Авыл хуҗалыгы оешмасы соравы буенча документлар күчермәләрен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы авыл

хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе бирә. Әлеге номинациядә барлык алдынгылар (14 кеше) бердәй күләмдә 3 448әр сум акча белән бүләкләнә (әлеге номинация буенча бүләкләүнең гомуми суммасы - 48 272 сум);

3.14. Бүләкләүләрнең барлык (гомуми) суммасы 2 998 156 сум тәшкил итә.

## 4. Конкурс комиссиясенә бирү өчен кирәкле белешмәләр

4.1. Конкурска йомгак ясау өчен мәгълүмат:

а) "Бөртекле культураларны урып-җыюда алдынгы комбайнчылар" номинациясендә катнашу өчен (3.1 пункт).) комбайнчыларның комбайн маркасын һәм тонналарда суктыруны күрсәтеп, эш күрсәткечләрен бирергә кирәк (2 кушымта);

б) «Шикәр чөгендерен җыюда алдынгы механизаторлар» номинациясендә катнашу өчен (3.2 пункт).) казылган гектарларны күрсәтеп, шикәр чөгендерен җыюда механизаторларның эш күрсәткечләрен бирергә кирәк (3 кушымта);

в) «Шикәр чөгендерен төяп озатуда алдынгы механизаторлар» номинациясендә катнашу өчен (3.3 пункт) казылган шикәр чөгендерен төяүдә механизаторларның эш күрсәткечләрен (тонналарда) бирергә кирәк (4 кушымта);

г) «Чәчүлекләрне корткычларга каршы сиптерүдә алдынгы механизаторлар» номинациясендә катнашу өчен (3.4 пункт) механизаторларның трактор маркасын һәм корткычларга, авыруларга һәм чүп үләннәренә каршы эшкәртүдә башкарылган эшләр күләмен күрсәтеп, эш күрсәткечләрен бирергә кирәк (5 кушымта);

д) «Туфракны чәчү алдыннан эшкәртүдә, уҗым культураларын чәчүдә һәм ашламалар кертүдә алдынгы механизаторлар» номинациясендә катнашу өчен (3.5 пункт).) механизаторларның эш күрсәткечләрен, трактор маркасын һәм туфракны чәчү алдыннан эшкәртүдә һәм чәчүдә башкарылган эшләр күләмен гектарларда күрсәтеп, механизаторларның эш күрсәткечләрен күрсәтергә кирәк (6 кушымта);

е) «Печән чабуда алдынгы механизаторлар» номинациясендә катнашу өчен (3.6 пункт) тракторның маркасын һәм печән чабуда башкарылган эш күләмен гетарларда күрсәтеп, механизаторларның эш күрсәткечләрен бирергә кирәк (7 кушымта);

ж) «Терлек азыгы әзерләүдә алдынгы механизаторлар» номинациясендә катнашу өчен (3.7 пункт) тракторның маркасын һәм тонналарда азык әзерләүдә башкарылган эш күләмен күрсәтеп, механизаторларның эш күрсәткечләрен бирергә кирәк (8 кушымта);

з) «Туфрак эшкәртүдә алдынгы механизаторлар» номинациясендә катнашу өчен (3.8 пункт) тракторның маркасын һәм физик һәм эталон гектарларда туфрак эшкәртүдә башкарылган эшләр күләмен күрсәтеп, механизаторларның эш күрсәткечләрен бирергә кирәк (9 кушымта);

и) «Алдынгы машина йөртүчеләр» номинациясендә катнашу өчен (3.9 пункт) техниканың төрен һәм тонна-километрларда ташылган йөкнең күләмен күрсәтеп, авыл хуҗалыгы продукциясен ташуда машина йөртүчеләрнең эш күрсәткечләрен бирергә кирәк. (10 кушымта);

к)«Машина белән сыер саву буенча алдынгы операторлар» номинациясендә катнашу өчен (3.10 пункт) тулаем савымны, беркетелгән

терлекләр санын, 2020 елның 9 аена 1 сыерга савымны күрсәтеп, машина белән сыер саву операторларының эш күрсәткечләрен бирергә кирәк (11 кушымта); Нәтиҗә бер сыердан савылган сөт буенча бәяләнә. Күрсәткечләр тигез булганда, эш стажы исәпкә алына.

л) «Алдынгы терлекчеләр һәм бозау караучылар» номинациясендә катнашу өчен (3.11 пункт) 2020 елның 9 ае өчен уртача тәүлеклек артымны, алынган тулаем артым санын күрсәтеп, терлекчеләрнең һәм бозау караучыларның эш күрсәткечләрен күрсәтергә кирәк (12 кушымта); күрсәткечләр тигез булганда, эш стажын исәпкә алырга.

м) «Авыл хуҗалыгы җитештерүе алдынгылары» номинациясендә катнашу өчен (3.13 пункт) комиссиягә бүләкләү турындагы документларның күчермәләрен тапшырырга кирәк: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Рәхмәт хаты, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы Рәхмәт хаты, министрлыклар һәм ведомстволарның, муниципаль район башлыгының Мактау грамоталары, «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» мактаулы исеме;

н) «Җитештерү комплексының һәм хуҗалыкның иң яхшы җитәкчесе» номинациясендә катнашу өчен (3.22 пункт) авыл хуҗалыгы оешмалары бүлекчәләренең эш күрсәткечләрен 2020 елга эш йомгаклары буенча ирешелгән күрсәткечләрне күрсәтеп бирергә кирәк (бөртекле культуралар буенча уңыш, шикәр чөгендере уңышы, 1 сыердан савылган сөт, ит җитештерү) (13 кушымта).

## 4. Грант суммаларын түләү тәртибе

5.1. Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашкан 2020 ел эш йомгаклары буенча иң югары нәтиҗәләргә ирешкән хезмәткәрләрнең исемлеге белән конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә җибәрелә.

5.2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге 5 эш көне дәвамында 2020 елгы эш йомгаклары буенча иң югары нәтиҗәләргә ирешкән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре хезмәткәрләренең исәп-хисап счетларына, Россия Федерациясе Салым кодексының 207 статьясы нигезендә физик затлар керемнәренә салымны (НДФЛ) тотып калып, акчаларны күчерә

## 6. Хисапка таләпләр

6.1. Грант суммасын алучы бирелгән документларның дөреслеге өчен җаваплы.

## 7. Грант суммасын бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

7.1. Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органнары грант суммасын бирүнең нигезләрен һәм шартларын мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

7.2. Конкурста катнашучы авыл хуҗалыгы оешмасы, акчалата средстволар бирүче вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан грант суммасын бирү нигезләрен, шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәү өлешендә мәҗбүри тикшерү уздыру өчен, кирәкле барлык документларны тапшырырга тиеш.

7.3. Гариза бирүче, шулай ук конкурста катнашучы авыл хуҗалыгы оешмасы тарфыннан әлеге нигезләмәдә билгеләнгән конкурсның шартлары һәм нигезләре бозылган очракта, вәкаләтле орган акчаларны кире кайтару турында карар кабул итә.

7.4. Вәкаләтле органнар (яисә) муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының хокук бозулары ачыклаган очракта, шулай ук конкурста катнашучы авыл хуҗалыгы оешмасы тарафыннан әлеге нигезләмәдә билгеләнгән конкурсның шартлары һәм нигезләре бозылуны ачыклаган очракта, идарәдән һәм (яисә) муниципаль финанс контроле органнарыннан акчаларны кире кайтару кирәклеге турында хәбәрнамә алынган соң 30 банк көне эчендә, акчалата түләүне алучы вәкаләтле органның шәхси счетына акчаны күчерү юлы белән муниципаль бюджетка акчаларны кире кайтарырга тиеш.

7.5. Грант алучы ихтыярый төстә аны түләүдән баш тартса, ул Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

Татарстан Республикасы Зәй
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның 11 ноябрь
506 номерлы карарына
2 нче кушымта

«2020 елда Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәре» конкурсына йомгак ясау буенча комиссия составы.

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Захарова М.И. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы |
| Сәхапова А.Ф. | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зәй муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге консультанты, комиссия секретаре (килешү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Архипова Р.М. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Камалиев Ф.Т. | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зәй муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Рәхмәтов М.Х. | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зәй муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе ПМО консультанты (килешү буенча) |
| Хәмидуллин Ш.Ф. | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зәй муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе ПМО башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмитова А.Г. | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зәй муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе ПМО 2 разрядлы өлкән белгече (килешү буенча) |
| Дубровина О.И. | - | "Зәй муниципаль районы" муниципаль берәмлеге иҗтимагый Советы әгъзасы, шәхси эшмәкәр |

«Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәре» нигезләмәсенә 1 кушымта
11.11.2020 ел №506

# «2020 елда Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәре» район конкурсында катнашуга гариза

________________________________________________авыл хуҗалыгы оешмасы
________________________________________________________________
исеменнән______________________________________________________________ номерлы карары белән расланган Башкарма комитет җитәкчесенең 2020 елның __ __________ __ «2020 елга Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәре» конкурсында катнашучылар составына кертүегезне сорыйм. «Зәй муниципаль районының 2020 елда иң яхшы агросәнәгать комплексы хезмәткәре» конкурсы нигезләмәсе белән танышумны раслыйм.

Түбәндәгеләрне раслыйм:

1. ________________ авыл хуҗалыгы оешмасы – юридик зат бетерелү, үзгәртеп кору, банкротлык процессында түгел.

2. Авыл хуҗалыгы оешмасы чит ил юридик заты түгел, шулай ук устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше, тулаем алганда, 50 проценттан артып китә торган, аның теркәү урыны-дәүләт (территория), Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яисә) финанс операцияләрен (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләт һәм территорияләр исемлегенә кертелгән Россия юридик заты булып тормый.

3. Авыл хуҗалыгы оешмасы конкурс үткәрү турында нигезләмәдә күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алучы булып тормый.

4. Авыл хуҗалыгы оешмасының Татарстан Республикасы бюджетына башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдындагы башка срогы чыккан бурычларны кайтару буенча срогы чыккан бурычы юк.

5. Авыл хуҗалыгы оешмасының салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеналар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк.

6. Авыл хуҗалыгы оешмасы бетерелү, үзгәртеп кору процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, катнашучының эшчәнлеге РФ кануннарында каралган тәртиптә туктатылмаган.

7. Программада катнашу шартлары белән таныштым һәм килешәм.

Тәкъдим ителгән документларда яисә заявкага күчермәләрдә барлык мәгълүматлар дөрес һәм грант бирүгә документларны карауда катнашучы затларның аннан файдалануына ризалыгымны бирәм.

«____» __________20__ ел

___________ /_____________ /
(имза) (Ф.И.А.)

М.У.

«2020 елда Зәй муниципаль районы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәре» конкурсында катнашуга заявкага 1 нче кушымта

**Тикшерүләр уздыруга ризалык**

______________________________________________________________________

(оешманың тулы исеме)

Авыл хуҗалыгы оешмасы үз ризалыгын бирә:

бюджет акчаларын баш бүлүчегә (бүлүчеләргә) (Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты) һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органына грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыруга.

Юридик зат җитәкчесе

____________________ _______________

(ФИА) (имза)

М.У.

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 2 кушымта
"___"_______________ 2020 ел.

## Комбайнчыларның ашлык җыюдагы эш күрсәткечләре

_______________________

| № | Ф.И.А. (тутырып) | Комбайн маркасы | Эш стажы | Суктырылган, тонналарда |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |
| 6 | | | | |
| 7 | | | | |
| 8 | | | | |
| 9 | | | | |
| 10 | | | | |
| 11 | | | | |
| 12 | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе

Баш икътисадчы

МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 3 кушымта
"___"______________ 2020 ел

**Шикәр чөгендерен җыюда механизаторларның эш күрсәткечләре**

______________________________

| № | Ф.И.А.<br>(тутырып) | Эш стажы | Казылган, га |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |
| 5 | | | |
| 6 | | | |
| 7 | | | |
| 8 | | | |
| 9 | | | |
| 10 | | | |
| 11 | | | |
| 12 | | | |

Хуҗалык җитәкчесе
Баш икътисадчы

МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 4 кушымта
"___"______________ 2020 ел.

**Шикәр чөгендерен төяүдә механизаторларның эш күрсәткечләре**

____________________________

| № | Ф.И.А. (тулысынча) | Эш стажы | Казылган, тонналарда |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |
| 5 | | | |
| 6 | | | |
| 7 | | | |
| 8 | | | |
| 9 | | | |
| 10 | | | |
| 11 | | | |
| 12 | | | |

Хуҗалык җитәкчесе
Баш икътисадчы

МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 5 кушымта
"___"______________ 2020 ел

**Ашлама сиптерүдә механизаторларның эш күрсәткечләре**

______________________________

| № | Ф.И.А. | Техниканың маркасы | Эш стажы | Мәйдан, га |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |
| 6 | | | | |
| 7 | | | | |
| 8 | | | | |
| 9 | | | | |
| 10 | | | | |
| 11 | | | | |
| 12 | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе
Баш икътисадчы

МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы
территориясендә авыл хуҗалыгы
эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы
предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү
турында нигезләмәгә 6 кушымта
"___" _______________ 2020 ел

**Механизаторларның туфракны чәчү алдыннан эшкәртү,көзге культуралар чәчү һәм ашламалар кертү буенча эш күрсәткечләре**

______________________________

| № | Ф.И.А. | марка | стаж | Башкарылган эшләр күләме |
|---|---|---|---|---|
| | | | | га |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |
| 6 | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе
Баш икътисадчы
МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 7 кушымта
"___"_______________ 2020 ел

**Механизаторларның чабуда эш күрсәткечләре**

_______________________________

| № | Ф.И.О. | марка | стаж | Башкарылган эшләр күләме |
|---|---|---|---|---|
| | | | | га |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |
| 6 | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе
Баш икътисадчы
МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 8 кушымта
"___"_______________ 2020 ел

**Терлек азыгы әзерләү буенча механизаторларның эш күрсәткечләре**

______________________________

| № | Ф.И.А. | марка | стаж | Башкарылган эшләр күләме |
|---|---|---|---|---|
| | | | | тонналарда |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе
Баш икътисадчы
МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 9 кушымта
"___"_______________ 2020 ел

**Туфрак эшкәртүдә механизаторларның эш күрсәткечләре**

___________________________

| № | Ф.И.А. | Техника маркасы һәм агрегат составы | стаж | Башкарылган эшләр күләме | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | га | Эт.га |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| 4 | | | | | |
| 5 | | | | | |
| 6 | | | | | |
| 7 | | | | | |
| 8 | | | | | |
| 9 | | | | | |
| 10 | | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе

Баш икътисадчы

МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 10 кушымта

"___"______________ 2020 ел

**Машина йөртүчеләрнең эш күрсәткечләре**

___________________________

| № | Ф.И.А. | Техник төре | Эш стажы | Ташылган йөкнең күләме-тонна километрларда. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |
| 6 | | | | |
| 7 | | | | |
| 8 | | | | |
| 9 | | | | |
| 10 | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе

Баш икътисадчы

МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 11 кушымта
"___"______________ 2020 ел

**Ел башыннан алып 2020 елның 1 октябренә кадәр машина белән сыер саву операторларының эш күрсәткечләре**

| № | Ф.И.А. | Эш стажы | Тулаем савым, цн | Терлеклщрнеж беркетелгщн баш саны | Бер сыерга савым, кг |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| 4 | | | | | |
| 5 | | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе

Баш икътисадчы

МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 12 кушымта
"___" _______________ 2020 ел

**Ел башыннан алып 2020 елның 1 октябренә кадәр терлекчеләрнең һәм бозау карауларның эш күрсәткечләре**

| № | Ф.И.А. | Эш стажы | Тулай артым, цн | Уртача тәүлеклек үсеш, гр. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |
| 5 | | | | |
| 6 | | | | |
| 7 | | | | |
| 8 | | | | |
| 9 | | | | |
| 10 | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе

Баш икътисадчы

МУ

2020 елда Зәй муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турында нигезләмәгә 13 кушымта
"___"______________ 2020 ел

**Җитештерү комплексының һәм хуҗалыкның эш күрсәткечләре**

______________________________

| № | хуҗалык җитәкчесе, җитештерү комплексы җитәкчесенең Ф.И.А. | Бөртеклеләрнең тулай җыемы, тонналарда | Бөртекләр уңышы, цн/га | Шикәр чөгендереңнең тулай җыемы, тонналарда | Шикәр чөгендере буенча уңыш, цн/га | Тулаем савым, цн 1.10.2020 | Тулаем артым, цн 1.10.2020 | Беркетелгән баш саны, | 1 сыерга савым, кг | Башлангыч мөгезле эре терлек башына үстерелгән, кг |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | | |
| 5 | | | | | | | | | | |

Хуҗалык җитәкчесе

Баш икътисадчы

МУ